МБДОУ «Детский сад» общеразвивающего вида с приоритетным осуществлением деятельности по познавательно-речевому направлению развития детей №59 «Дружба»

# “Теплые объятия моей мамы”

**Сценарий развлечения для старшей группы**


Составила муз. руководитель:

Уметбаева Эльмира Амирзяновна.

II кв. категория


Набережные Челны

2015

# “Әниемнең җылы кочагы”

*Зурлар төркеме өчен*

*Матур итеп киенгән балалар, әниләре белән залга керәләр.. Зал буйлап түгәрәк ясыйлар.*

***Алып баручы:*** Кадерле әниләр, әбиләр, апалар!  Бүген ,балаларыбыз сезне , бәйрәм белән котларга җыелдылар. Бәйрәмебезне вальс белән башлап җибәрик.

*Малайлар һәм кызлар әниләрен вальска чакыралар.*

ВАЛЬС.

*Әниләр һәм әбиләр урыннарына утыралар, балалар ярымтүгәрәк ясап басалар*.

**1 бала:** Нигә бүген бөтен җирдә

Чәчәкләр балкый бездә.

Нигә кояш көлеп карый

Беләбез һәммәбез дә.

**2 бала:** Килеп җитте 8 Март,

Әниләр бу сезнең көнегез.

Сез үстергән балалардан бүген

Кайнар котлау кабул итегез.

**3 бала:** Безне назлап үстергәнгә,

Әниләр рәхмәт сезгә.

Һәрвакыт эшчән булганга,

Әниләр рәхмәт сезгә.

Һәрвакыт тырыш булганга

Әниләр рәхмәт сезгә.

**4 бала:** Җырым бүләк итәм әнием сиңа,

Онытылмас гомер-гомергә.

Бу җырымны сиңа багышладым

Җырлыйм аны сиңа бүген дә.

***Әниләр турында ҖЫР***.

*(Җыр бетүгә, мотор тавыша ишетелә)*

**Алып баручы**: Ай, балалр, нәрсә бу? Кемдер безнең бәйрәмгә ашыга ахрысы.

*(Велосипедын этеп Кәрлә килеп керә, кабызмакчы була, кабынмый)*

**Алып баручы**: Нәрсә булды? Балалр бу Кәрлә икән бит.. Ул мәктәп баласы. Нишләп йөрисең монда? Балалар әйтегез әле, велосипедны кабызып буламы?

**Балалар:** Юк. Аның бит моторы юк.

**Кәрлә:** Ничек инде юк? Менә бит др-р-р-р...

**Алып баручы:** ярый инде сезнеңчә булсын. Исәнме Кәрлә!

**Кәрлә:** Исәнмесез балакайлар, шаянкайлар, малайлар һәм кызыкайлар.

**Алып баручы**: Исәнме. Исәнме, Кәрлә! Бик күптән инде бездә күренмәдең. Кунакка да килмисең.

**Кәрлә**: беләсезме, бер дә вакытым юк бит. Эшем күп шундый. Мин бит инде – Кәрлә мәктәп баласы. Ничә ел инде беренче класста утырып кара әле син. Күпме балалар белән таныштым. Миңа мәктәптә тәмле ашатулары гына ошый.

**Алып баручы:** Әй. Син, Кәрлә. Тик эшкә өйрәнә алмыйсың, һаман шундый тәмле тамак икәнсең. Ә без балалар белән, синең килүеңә бик шат.

**Кәрлә:** Мин дә бик шат. Сез дә, мин дә шат. Әйдәгез алайса, бергә утырым мультфильм карыйк.

**Алып баручы:** Тукта әле, нинди карау ди. Бүген бездә бәйрәм бит.

**Кәрлә:** нинди бәйрәм?

**Алып баручы**: Сигезенче март – Әниләр бәйрәме.

**Кәрлә:** Тагын да әйбәтрәк, димәк барыбыз бергә, әниләр белән дә, әбиләр белән дә бергә мультфильм карыйбыз.

**Алып баручы:** Тукта әле Кәрлә. Күрәсеңме күпме кунак килгән, безнең бәйрәм программабыз да әзер түгел әле.

**Кәрлә:** Ә сез беләсезме соң, кыенлыклардан тиз чыгу юлын кем таба?

**Алып баручы:** Бу бәлки синдер Кәрлә?

**Кәрлә:** Юк ла. Ничә ел инде беренче класста укып карагыз. Башың эшләр җиреннән эшләмәс. Бу Убырлы Дибаевна.

**Алып баручы:** Убырлы? Йә, ярар мактама әле Убырлыны, ул явыз эшләр генә эшли белә. Кәрлә: Сез нәрмә инде, аннан да акыллы зат юктыр, хәзер шалтыратам.

(*Кәрлә, Убырлы Дибаевнага шалтырата)*

**Кәрлә:** Алло, алло! Исәнмесез!. Миңа Убырлы Дибаевна кирәк иде, чакыра алмассыз микән?

**Убырлы:** (*яздырылган тавыш*) . Әйе-әйе, тыңлыйм сезне.

**Кәрлә:** Ә-ә-ә-әй , сәлам убырлы.

**Убырлы:** Син мени әле бу Кәрлә.

**Кәрлә:** мин инде, мин. Мин балалар бакчасында.

**Убырлы**: Бер дә аптырамыйм, беренче класстан икенче класска күчә алмагач, балалар бакчасына бармыйча булдыра алмассың.

**Кәрлә:** Миңа синең ярдәмең кирәк. Балаларга бик кызык итеп бәйрәм программасы ясарга иде.

**Убырлы:** Ярар балалар теләгәчч, хәзер килеп җитәрмен.

*(мотор тавышы. Убырлы керә)*

**Убырлы:** Исәнмесез, балалар. Мин Убырлы Дибаевна булам. (баш иеп исәнләшә)

**Кәрлә:** Балалар һич тә телевизор карарга теләмиләр.Бәйрәм ял итеп үтәргә тиеш инде.

*(Убырлы арлы-бирле йөри.)*

**Убырлы:** Мин сезгә балар, барыбер телевизор карарга тәкъдим итәр идем.Ләкин ул безнең тылсымлы булачак. Барлык тапшырулар да сез катнаша аласыз. Ә мин инде, соң мин – алып баручы... йә ничек?

**Алып баручы:** Ярый алайса без риза, шулай бит балалар? Димәк башлыйбыз?

Кәрлә: Ә мин сезне үземнең "Самсунг" телевизорыннан карап торырмын.

*(Йөгереп чыгып китә)*

**Убырлы:** Минем гримны әйбәтләгез әле.. Йөзләрем ничек, киемем? *(кызлар матурлый)*

**Убырлы:** Исәнмесез, кадерле телевизор карауччылар! Бүгенге бәйрәм көнендә 59 нчы балалар бакчасының 11 нче төркем каналы сезгә 8 март бәйрәменә багышланган тапшыру тәкъдим итә. Туры элемтәне кушабыз.

**1 бала:** Аяклар тими идәнгә

Дәртләнеп биегәндә.

Йөрәкләр җырлый берләшеп

Парлашып биик әйдә.

***(Балалар башкаруында "Татар биюе")***

**Убырлы:** Үзебезнең тапшыруларыбызны дәвам итәбез. Безнең телевидениебезгә би-и-ик күп смс – хәбәрләр килә. Әәәә менә монысы Хат тапшыручы Печкиннан икән, посылка китерәм, көтегез дигән.

*( музыка тавышы ишетелә)*

**Печкин:** Дөрес килдемме? Миңа балалар бакчасы кирәк иде. Язгы бәйрәм монда утәме?

**Убырлы:** Әйе Печкин, син дөрес килгәнсең.

**Печкин:** Беренче хатым – балалар 59 нчы балалар бакчасыннан. Алар үзләренең әниләрен шушы бәйрәм белән котларга телиләр. Ә үзләренең теләкләрен алар җыр аша җиткерәләр.

**Убырлы:** Бүләккә җыр тапшыруы аша, балалар җылы тнләкләрен җиткерә.

***( ЖЫР)***

**Кәрлә:** Икенче хатны ачыйк, җитмәсә әле тартмасы да бар.. Беләм, беләм, монысы миңа.Монда кәнфитләрдер инде.

**Печкин:** Юк Кәрлә, бу хатлы тартма Яз кызыннан.. ләкин тартманы мин сезгә болай гына бирмим.

**Убырлы:** Яхшы алайса, балалар үзегезнең уңганлыгыгызны күрсәтегез әле.

**1 бала:** Яз килә, яз килә

Елмая, көлә кояш.

Илебез буйлап атлый

Чәчәкле ай, матур яз.

**2бала:** Тамчы бии тып та тып,

Тамчылар сикерәләр.

Аларны булмый туктатып

Алар Яз китерәләр.

**3 бала*:*** Аксакал кыш инде озак тормас

Вакыт уза, китә ул бездән.

Шаулап – гөрләп капчыклары белән

Кояшлы яз килер яңадан.

***(ҖЫР)***

**Убырлы:** Балалар синең биремне үтәде Печкин.

**Печкин**: Әйе, бик матур сөйләделәр. Тартма сезнеке.

*(тартманы эзли)*

**Печкин:** Кая соң әле ул тартма. Мин аны сезә тапшырам дип сумкама тыктым. Нишләргә инде хәзер. Яз кызының биләмәләренә кире кайтам инде. Бәлки шунда табармын.

**Убырлы:** Техник җитешмәүчәнлекләр аркасында программабыз авырлыклар кичерә. Ләкин без моңсуланмыйбыз, Яз кызын – үзен бирегә чакырыйк.

**Балалар:** Яз кызы! Яз кызы!

*(матур көй астына Яз кызы керә)*

**Яз кызы:** Исәнмесез балалар! Минем якын дускайларым. Мин Яз кызы. Мин урман, кырларны, басуларны, кышкы йокыдан уятам. Ә сезгә җылы көннәр алып килдем.

**Алып баручы:** Исәнме Яз кызы!.

Рәхим ит, түрдән уз!

**1 бала:** Әй, Яз матур, Яз- матур!

Хуш киләсең, үз бире.

Кунак булып килер дип,

Күптән көттек без сине.

**2 бала:** Әй, Яз-матур, Яз-матур!

Хуш киләсең үз бире.

Шатланышып җыр белән

Каршылыйбыз без сине.

***( ЯЗ ТУРЫНДА ҖЫР, рус телендә)***

**3 бала:** Асыл кошлар ояда

Оялары пыяла.

Уйнамыйча, шаярмыйча,

Кем яшәгән дөньяда.

**Яз кызы:** Дөрес, балалар. Әйдәгез әле бер уйнап алыйк.

***Татар халык уены "Түбәтәй***.

*Залга ачулана, ачулана Әби керә.*

**Әби:** Бу нинди хәл бу. Яңа өйләрне җыештырып чыктым гына бит әле. Бу кем индек тагын. Чык әле ул тартмадан тизрәк.

**Убырлы:** Ярар, ярар, хәзер чыгам. Югыйсә безнең телевизорны бөтенләй эштән чыгара.

Әби: Чык дим, чык. Бөтен җирдәге тузаннарны сөртеп чыктым. Син каян килеп чыктың? Кибеткә күптән кергәнең юк мы әллә, кара инде өс-башыңны. *(киемен карый)*

**Убырлы:** Нәрсә булган киемемә? Бик матур. Ә сезгә тынычланырга киңәш итәр идем. Шундый уңган, шундый булган хатын-кыз мондый көндә ачуланып йөрергә тиеш түгел инде.

**Әби**: Нинди көн?

**Убырлы:** Балалар, әбекәйгә әйтегез әле.

**Балалар**: 8 Март- хатын-кызлар бәйрәме.

**Әби**: Эх, яшь чаклар, кесә тулы борчаклар. Идәннәргә баса-баса биесе килгән чаклар.

***(Татар көенә Әби белән Убырлы биилэр)***

**Әби:** Рәхәтләнеп тә биедем инде. Утырып торыйм әле.

**Убырлы**: Әбекәй, син беләсеңме, балалар үзләренең әниләрен ничек яратканны. Менә карап утыр.

***(уен "Үз балаңны тап)***

**Убырлы:** Әниләрен генә түгел, әбиләрен дә ничек яраталар алар.

**1 бала:** Минем әбием бик әйбәт

Гел көлеп кенә тора.

Балакаем диеп әйтеп

Сөеп иркәләп тора.

**2 бала:** Зәңгәр күгемдә ал кояш

Сүнмәсен, балкып янсын.

Әбиләрнең нурлы йөзе

Гел көләч булып калсын.

**3 бала:** Ак яулыклы, көләч йөзле,

Шат күңелле, әйбәт тә.

Кем ул диеп сорыйсызмы?

Дәү әнием әлбәттә.

***(Әби турында җыр)***

**Яз**: Балалр, сез шундый уңганнар. Бәйрәмегез шундый матур булды. Әниләргезне, әбиләрегезне бигрәк матур котладыгыз. Тик менә Печкин гына минем сезгә дип әзерләгән бүләгемне югалткан. Ә анда сезнең күчтәнәчләр иде.

**Әби**: Кайгырма, кызым! Минем сандыгым төбендә балаларга дип саклап тоткан күчтәнәчләрем бар.

*Сандыкны ачып әби белә Яз-кызы күчтәнәчләр тарата.*

**Алып баручы:** Рәхмәт, әбекәй. Рәхмәт, Яз кызы. Ттагын бер барыгызны да бәйрәм белән котлыйбыз.

*Әби белән Яз кызы һәм Убырлы рәхмәт әйтеп чыгып китәләр.*

*Балалар зал тирәли әйләнеп, музыка астына төркемгә чыгалар.*